

Ләмберә районы Татар Свербеевка авылында яшәvче Ариковлар хужалыгында барлыгы унсигез баш могезле хайван. Аларнын икесе – саудыра. Бу хужалыкта эш кайнап тора. Хезмәт – тормышнын мәгънәсе. Хезмәт тобе – хәзинә. Кеше бу сvзләрне гомере буе дәлилли. Равилә ханым да эшсез торырга яратмый. Букадәр зур хужалыкта таза ир-ат та коч-хәл белән булдыра, ә биредә яшь хатын эшли, әмма ирләрдәгечә корычтай нык характерлы ул. Мал-туарны, файда китерсен дисән, яхшылап тәрбияләргә, ашатырга кирәк. Алтмыш сотка жирдә кvп әйбер vстереп булмый шул. Шәхси хужалыклардан сатып алып малларны тукландырырга туры килә ана.      - 20 тоннага якын печәнне Рузаевкадагы бер хужадан сатып алдым. Ул хужалыгын таратып, Мәскәvгә китәргә жыенган. Коне саен шулкадәр кvп эшне башкарырга коче житмәгән. Анардан ук Настя исемле тиктормас сыерны да сатып алдым, - сыерын савудан туктамыйча аралаша Равилә ханым, - Ромодановадан жом ташыйм, Саранск пивзаводыннан -  барда. Бәягә тошә  жом, сигез мен сум тоннасына бирәм, ә барда - 800 сумнан. Боларсыз югары сыйфатлы сот алу кыен.

Ариковлар хужалыгында йок машинасы бар, ә тәгәрмәчләрне хужабикә vзе әйләндерә. Элек тракторны да vзе ук жиккән. Хәзер кирәге булмаганлыктан саткан. Хайваннарын vстерvдән башка Равилә Абдулла кызынын тагы бик тә жаваплы эше бар: соттән эремчек белән каймак ясый. Алар сатуда бик тә популяр - эх иткәнче сатылып бетә. Клиентларынын кайберләренә, мәсәлән, Саранск шәһәрендә яшәv-челәренә, жинел машинасында сотне, каймакны һәм эремчекне хужабикә vзе илтеп тә бирә.

Ничекләр генә олгерә икән бу хужабикә дигән сорау тынгы бирми. Беренчедән, Наиль Каюм улы булыша. «Эшсез бер минут та торырга туры килми, - ди Наиль Каюм улы Нарбеков, - мин унбиш ел пенсиядә, Равилә Арикованын двоюродный сенеле (минем тормыш иптәшем) соралганга ярдәм итәм Равилә Абдулла кызы Арюковага. Оч ел инде тормыш иптәшем авариягә эләгеп vлгәненә, инвалид улым тәрбиямдә. Хужабикәнен дә тормыш иптәше авариягә эләккән иде, эшкә ярамый. Менә шулай мин хужалыкта эшлим».

Ә топ авырлык, әлбәттә, хужабикә жилкәсендә. Равилә ханым иртә торып сон гына йокларга ятарга кvнеккән. Юкка әйтмиләр: кем сон йокларга ята һәм иртә тора, ул бәхет, байлык һәм акыл жыя, - диләр.

- Кармелита дигән сыерыбыз бик тә сотле, коненә утыз литрдан артык саудыра, - ди Равилә Абдула кызы Арикова. Ике кыз бала тәрбияләп vстердем, бvген vзләре балалар тәрбиялиләр. Регинамнын бер баласы, ә Зульфиямнен оч баласы; оныкчыгым туды. Бvгенге чорда яшьләргә аякка басарга ярдәм итәргә кирәк. Эшкә ойрәнгән бит мин.

Эштән курыкмыйм. Хезмәт - тормышынын мәгънәсе ул.  Совхозда доярка булып хезмәт иткән әниемә ун яшемнән ярдәм итә башладым, сыерлар савыштым. Сонышнан агрономлык профессиясен vзләштердем. Диплом алгач, белгечлегем буенча агроном булып совхозыбызга эшкә урнаштым. Донья бер жирдә генә басып тормый; һәр кон ниндидер vзгәреш була. Шулай, заманалар vзгәрде, совхозлар таралды, эш урыннары югалды. Татар Свәрбиеннән дә кvпләре Саранск шәһәренә эшкә киттеләр, ә Равилә ханым шул вакыт киләчәген шәхси хужалык белән бәйли. Хокvмәт тә шул эшләргә нык игътибар бирә: эшлә, тырыш, иренмә генә. Әмма яшьләр коне-тоне, ялсыз эшләргә бик ук ашыкмыйлар, шунысы аяныч. Татар Свербейкасында тик Арикова һәм дә Венера ханым Богданова мал-туар vрчетv белән шогыльләнәләр.
- Аллага шокер, мина бу авыр эшне жинеп чыгарга коч бирелә, - ди Равилә ханым. - Кочем житкәнче шәхси хужалыгымны алып барырга жыенам. Шулкадәр ойрәнелгән инде бу эшләргә, тормышымны башкача кvз алдыма да китерә алмыйм. Белсәгез, бар иде вакытлар, кибеттә дә эшләдем, ит тә саттым, әмма бvгенге эшемне табуыма бик тә канәгать мин.
Кибет киштәләреннән сот продуктлары сатып алган вакытта анын ялтыравыклы кәгазенә тvгел, ә составына игътибар итәргә кирәк. Хәзер бик кvп химия ашыйбыз, шуна кvрә торле чирләр дә артты. Составында пальма, кокос мае һәм башка кушылмалар булган коры соткә караганда vзебездә житештерелгән сыйфатлы продукция куллансак файдалырак та, тәмлерәк тә. Шәхси хужалыкта житештерелгән ашамлыклар экологик яктан чиста, дару тосле. Равилә Абдулла кызы Арюкованын якташлары тиз арада сот, эремчек, каймак, йомыркаларын сатып алып та бетерәләр; яраталар ашамлыкларын. Авыл дигәч, торле кеше яши бередә. Әйтеп китәргә кирәк, кемнәрдер Ариковларга кончелек белән карый; тормышка жинел яраклашканнар, диючеләр дә табыла. Андыйлар vзләре тырышу, жин сызганып якты таннан карангы тонгә кадәр эшләv дигәнне белмиләр. Наиль Каюм улы Нарбеков әйтмешли: «Тел кайрау - аларнын профессияләре, эш кенә сорама vзләреннән. Эчкечелек тә аларны аяктан йоккан. Кем аларга чын эш белән шогыльләнергә комачаулаган? Татарларыбызда юкка гына әйтмиләр: тырышкан табар, ташка кадак кагар. Бvген vз коченә таяныр заман: матур яшәргә теләсән, тырышып кына эшлә, шунда синен тормышында да торле яктан яхшы булыр. Хезмәт тобе хәзинә бит!»

**Н.Хәлил**